ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.06.2022 ел Баулы шәһәре №101

2022 елга Баулы муниципаль районының муниципаль учреждениеләрендә хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство контроле планын раслау турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы 353.1 статьясы, Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының хезмәт хокукы нормалары булган хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыру турында» 2020 елның 25 маендагы 115 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы 2022 елга Баулы муниципаль районының муниципаль учреждениеләрендә хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство контроле планын расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 2 июнендәге
101 номерлы карары белән
расланган

2022 елга Баулы муниципаль районының муниципаль учреждениеләрендә хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство контроле
ПЛАНЫ

| № п/п | Эшчәнлеге план буенча тикшерелергә тиешле ведомство учреждениеләре | | | Планлы тикшерүне үткәрү срогы |
|---|---|---|---|---|
| | Наименование учреждения | Оешманың юридик һәм фактик адресы | ИНН/ ОГРН | |
| 1. | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Алсу» 1 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | 423930, Татарстан Республикасы, Баулы ш., Һади Такташ ур., 11 й. | 1611004868/ 161101001 | 2022 елның II кварталы |
| 2. | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Колокольчик» 7 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | 423930, Татарстан Республикасы, Баулы ш., Ваһапов ур., 37 й. | 1611004882/ 161101001 | 2022 елның III кварталы |
| 3. | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Мәгариф бүлегенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе | 423930, Татарстан Республикасы, Баулы ш., Җиңү мәйданы, 5 й. | 1611290626/ 161101001 | 2022 елның IV кварталы |
| 4. | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесе | 423930, Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Җиңү мәйданы, 4 й. | 1611002853/ 161101001 | 2022 елның IV кварталы |

________________________